СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«28» декабрь, 2023 ел Алабуга шәһәре № 321

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәт вазифаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Алабуга муниципаль районында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 12 ноябрендәге 462 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2014 елның 12 ноябрендәге 462 номерлы карары белән расланган, Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәт вазифаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Алабуга муниципаль районында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 16 пункттагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләрнең үз чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, яисә уз чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, алдан ук тулы булмаган белешмәләр бирү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, яисә мондый белешмәләр бирү мәҗбүри булган очракта, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган

белешмәләр бирү хокук бозу булып тора, аларны алмаштырыла торган вазифаларыннан азат итүгә, муниципаль хезмәттән билгеләнгән тәртиптә эштән азат итүгә китерә.».

Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов